СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

_________________ с. Сарманово №_____________

22.05.2023 ел № 139

Сарман муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2023 елның 28 апрелендәге 154-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 5 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон (1-41 статьялар), «Сарман муниципаль районы» берәмлеге уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

**1.** Сарман муниципаль районы Советының 2013 елның 18 декабрендәге 132 номерлы карары белән расланган Сарман муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 21 статьяның 17 өлешендә «гамәлгә ашырыла» сүзен «гамәлгә ашырылырга мөмкин» сүзләренә алмаштырырга;

2) 30 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9) сатып алуда катнашучы чит ил агенты булмый»;

3) 32 статьяның 1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) сатып алу объекты тасвирламасында сатып алу объектының функциональ, техник һәм сыйфатлы характеристикалары, эксплуатацияләү характеристикалары (кирәк булганда) күрсәтелә. Сатып алу объекты тасвирламасында товар билгеләренә, хезмәт күрсәтү билгеләренә, фирма исемнәренә, патентларына, файдалы модельләргә, сәнәгать үрнәкләренә карата таләпләр яисә күрсәтмәләр, товарның килеп чыгышы иле исеменә, товарларга, мәгълүматка, эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә карата таләпләр алынмаска тиеш, мондый таләпләр яисә күрсәтмәләр сатып алуда катнашучылар санын чикләүгә китерәчәк. Сатып алу